Троицкий-Урай авыл җирлеге Советы

Балык Бистәсе муниципаль районы

Татарстан Республикасы

2 нче Карар

Троицкий Урай авылы 26.01.2026 ел

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Троицкий-Урай авыл җирлеге Советының 28.04.2023 елның 7 номерлы «җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында»карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Троицкий-Урай» авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына таянып, «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 28.11.2025 ел, №425-ФЗ Федераль закон нигезендә Совет Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Троицкий-Урай авыл җирлеген хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Троицкий-Урай авыл җирлеге Советының «җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 28.04.2023 елның 7 номерлы карарына (17.06.2024 №5, 23.12.2024 №15 редакциядә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. 1 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«1) физик затның Россия Федерациясе Граждан-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат булуы яисә вафат булуы турында игълан ителүе (мондый физик затка карата банкротлык турында эш кузгатылган очрактан тыш):

Россия Федерациясе Салым Кодексының 14 статьясындагы 3 пунктында һәм 15 статьясындагы 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелмәгән салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча бурычлар өлешендә;

Россия Федерациясе Салым Кодексының 14 статьясындагы 3 пунктында һәм 15 статьясындагы 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән салымнар буенча аның мирас мөлкәте хакыннан артыграк күләмдә, шул исәптән мирас Россия Федерациясе милкенә күчкән очракта да, бурыч өлешендә;

Россия Федерациясе Салым Кодексының 14 статьясындагы 3 пунктында һәм 15 статьясындагы 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән салымнар буенча аның мирас мөлкәте хакыннан артмаган күләмдә бурыч өлешендә мондый физик зат вафат булганнан соң өч ел узгач һәм салым органында мондый мөлкәтне мирас итеп алу факты турында мәгълүмат булмаганда;».

2. Әлеге карар 2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Троицкий-Урай авыл җирлегенең түбәндәге адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Троицкий Урай авылы, Кама буе ур., 9 йорт, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Гремячка авылы, Александров ур., 24и Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы» нда түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе

муниципаль район Троицкий Урай

авыл җирлеге башлыгы Мөхәммәтҗанов Р. М.